**Татарстан Республикасы**
**Зәй муниципаль районы**
**Кадер авыл җирлеге Советы**

# КАРАРЫ

23.03.2018 ел № 115

**«Җир салымы турында» 2014 елның 14 ноябрендәге 151 номерлы Зәй муниципаль районының Кадер авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Салым кодексының икенче өлеше 31 бүлеге нигезендә, Кадер авыл җирлеге Уставына таянып, Зәй муниципаль районының Кадер авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. «Җир салымы турында» 2014 елның 14 ноябрендәге 151 номерлы Зәй муниципаль районының Кадер авыл җирлеге Советы карарына (2015 елның 11 сентябрендәге 193 номерлы, 2017 елның 18 сентябрендәге 95 номерлы карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Салым ташламаларына хокуклы, шул исәптән салымнар һәм җыемнар турында законнарда билгеләнгән салым кайтаруы рәвешендә, салым түләүче физик затлар үзләре сайлау буенча салым органына салым ташламалары бирү турында гариза бирергә, шулай ук салым түләүченең салым ташламасына хокукын раслый торган документларны тапшырырга хокуклы».

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2018 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU), авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында һәм Зәй муниципаль районы рәсми сайтының «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

**Совет рәисе** **Р.М. Нуруллин**